СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«МӨЭМИН-КАРАТАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 апрель 2021 ел № 16

Мөкмин-Каратай авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск шәһәр прокурорының «Торак» илкүләм проектын тормышка ашыруны регламентлаучы закон таләпләрен тиешенчә үтәмәве турында күрсәтмәсен карап, Мөкмин-Каратай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Мөкмин-Каратай авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта «территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары» сүзләреннән соң «комплекслы үсешкә тиешле территорияне планлаштыру документлары проекты буенча» сүзләрен өстәргә,»;

3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 3.1 пункты белән тулыландырырга:

«3.1. Территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны тормышка ашыру өчен җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү таләп ителгән очракта, җирле администрация башлыгы карары нигезендә, җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча һәм комплекслы үсеш алырга тиешле территорияне планлаштыру документлары проекты буенча ачык тыңлаулар һәм (яки) җәмәгать фикер алышулары үткәрү рөхсәт ителә.»;

5 пунктта «территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары» сүзләреннән соң «комплекслы үсеш алырга тиешле территорияне планлаштыру документлары проекты буенча» сүзләрен өстәргә,»;

6 пунктны түбәндәге эчтәлекле икенче абзац белән тулыландырырга;

«Җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертелгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә,

иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар урамы, 35 Б адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Ә.А.Ханнанова